# АдымнарTimes

Полилингвальный образовательный комплекс
*«Адымнар-Нижнекамск»*

№ 1, декабрь 2022 г.

adymnartubenkama
adymnartubenkama





***Школу открывали: президент РТ Рустам Минниханов, госсоветник РТ Минтимер Шаймиев и министр образования и науки РТ Ильсур Хадиуллин***

## АНОНС


2 ***«Мы знали: школа будет!»:*** *фоторепортаж с открытия*

4 ***«Без галстука»: интервью с директором Артуром Галиахметовым***

7 ***«Бизнес в «Адымнар»: растим предпринимателей***

***ТАТАРЧА ЯЗАБЫЗ:***

3 ***«Разил Вәлиев бездә кунакта: очрашу мизгелләре»***

3 ***Кызыклы уеннар: «Тәрҗемә ит!»***

5 ***Артур Галиәхмәтов: «Минем миссиям – уңышка омтылыш уяту»***

6 ***«Шәхес: Эльвина Унверен. Истанбулдан – Түбән Камага»***




## Слово редактора



**УВАЖАЕМЫЕ ЧИТАТЕЛИ!**

**Вы держите в руках первый номер газеты «Адымнар TIMES».**

Уникальность нашей школы состоит в том, что ребята получают знания на разных языках. Поэтому и на страницах нашего издания вы встретите материалы на русском, татарском и английском языках!

Надеемся, вы не будете слишком строги – это наш первый опыт! Желаем приятного прочтения!

Күәфле укулар телим!

*С уважением, редактор газеты*
*Ксения ПУШКАРЁВА*

**У нас учатся почти 700 детей**
**У нас учат 40 учителей**

## Фоторепортаж с открытия

# МЫ ЗНАЛИ – ШКОЛА БУДЕТ!





**1 сентября, в День знаний,** состоялось торжественное открытие нашего полилингвального образовательного комплекса «Адымнар-Түбән Кама».

*«Адымнар-Түбән Кама»* – *Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе һәм «Возрождение» республика фондының Попечительләр советы әгъзасы Минтимер Шәймиевнең теләге буенча төзелгән Татарстандагы бишенче мәктәп.*



*Преподавание ведется на трех языках: русском, татарском и английском. Также дети посещают кружки французского, арабского, турецкого и китайского языков.*





**Наша философия гласит: «Думающие дети, обучающиеся учителя, поддерживающие родители»**



*«Адымнар» – прекрасная современная школа с просторными, светлыми, уютными классами, мастерскими, спортивным и актовым залами, столовой и т.д.*
*Все это позволит вам, дорогие дети, прикоснуться к удивительному миру науки, искусства, культуры и спорта, где вас всегда будут сопровождать ваши учителя-наставники!*

**Безнең фәлсәфәбез: «Локаль уйлыйбыз, глобаль эшлибез»**



## Татарча язабыз!

# Разил Вәлиев бездә кунакта

**23 нче октябрь көнне Түбән Каманың «Адымнар» полилингваль белем бирү комплексында хөрмәтле якташыбыз, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның күренекле халык шагыйре Разил Вәлиев премиясенә яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау кичәсе булды.**




Бәйрәмебез хуҗасы «Адымнар» мәктәбе укучыларының сорауларына да бик теләп җавап бирде:

***– Разил абый, Сезнең шигърият дөньясы белән бәйле нинди хыялларыгыз бар?***

– Синең шигырең укучыларга барып җитсә, шуннан да зуррак куаныч юк. Язу- ул, нихәтле генә күп язсаң да, әгәрдә укучылар күңеленә барып җитми икән, аны укучылар укымый икән, бу инде бик зур куаныч түгел.

**Ркаил Зәйдулла:** Безнең хыяллар – сезнең кебек яшьләр килсен иде.

**Илина:** Вакыт машинасы булса, үткәнгә кайтып, кайсы шагыйрь белән очрашырга теләр идегез һәм аңа нинди сораулар бирер идегез?

– Вакыт машинасы, билгеле, бик кызык машина инде ул. Хыял, хыял... Минем иң яраткан шагыйрем, кечкенә чактан ук, Һади Такташ булды. Минем Һади Такташ белән янәшә утырып серләр бүлешәсем, гаплəшәсем киләр иде.

**Илина:** Бүгенге көндә Сезгә кемнең иҗаты ошый?

– Әгәрдә берсен генә санасам, калганнары үпкәләр, шуңа күрә әйтмим.

**Азалия:** Яшь буын шагыйрьләренә нинди теләкләр әйтер идегез?

– Шигырь язганда иң беренче чиратта нәрсә турында уйларга кирәк? Туфан ага Миңнуллин, бик зур драматург – язучыбыз болай дип әйтә иде: «Язучының, бигрәк тә, татар язучысының иң төп темасы- ул милләт темасы, милләт язмышы, милләтебезнең, татар халкыбызның язмышы, туган телебезнең язмышы». Менә шушы проблемалар, шушы мәсьәләләр күбрәк борчысын иде.

**Илина:** Сез бүгенге көндә нинди өмет-хыяллар белән яшисез?

– Өметсез шайтан ди инде *(көлә)*...шуңа күрә, өметсез яшәп булмый, иң зур теләгем: исән-сау булу.

**Илина:** Беренче язган шигырегезне хәтерлисезме?

– Юк, хәтерләмим. Хәтерләмим инде, 4 нче сыйныфта укыганда, әнкәйнең туган көненә багышлап язылган иде, бик истә калырлык шигырь булмагандыр.

**Азалия:** Киләчәктә «Адымнар» мәктәбе укучыларына нинди теләкләр теләр идегез?

– Адымнарыгыз нык булсын, ышанычлы булсын! Сез, һичшиксез, бу мәктәпнең данын арттырырга тиешле укучылар!

***Зөлфия ЯЛАЛОВА, туган тел һәм әдәбият укытучысы,***
***Энҗе Зайдуллина фотосы***

# «Тәрҗемә ит!»

«Телне өйрәнү процессын ничек мавыктыргыч итәргә?» Без беләбез – уен белән! Татар телен өйрәнмәгән яки начар аңлаган балалар өчен без озын тәнәфесләрдә (20 минут!) кызыклы уеннар һәм чаралар үткәрәбез! Ә аларның ничек узуы турында безнең укытучыбыз сөйләр.

***Алина ИСМӘГЫЙЛОВА, милли мәгариф буенча директор урынбасары***






Бу уенда 1-нче Б, Г сыйныф укучылары бик теләп катнашалар. Уен барышында алар сүзләр, сүзтезмәләр тәрҗемә итәләр, төрле сорауларга җавап бирәләр, ә уен ахырында исә барысы бергә татарча җырлар башкаралар. Без, татар теле укытучылары, укучыларны шатланырга, җавапларыннан, эшләгән эшләреннән канәгать калырга һәм сәләтләрен үстерү өстендә дә эшләргә тырышабыз. «Тәрҗемә ит» уены укучыларга бик ошый. Аларның уен турында фикерләрен сезгә дә җиткерәсебез килә.

**Самира Исмәгыйлова (1Б):** Мин 3-нче тәнәфесне көтеп алам, чөнки без сыйныф җитәкчебез белән «Тәрҗемә ит» уенына барабыз. Анда көн саен яңа сүзләр белән танышабыз.

**Чулпан Шакирова (1Г):** Миңа сүзләрне тәрҗемә итү бик ошый. Уен ахырында без җырлыйбыз. Ә мин җырларга бик яратам.

**Хафизуллина Сафия (1Г):** 2 ай эчендә мин бик күп яңа сүз өйрәндем. Бигрәк тә Илназ Сәфиуллинның «Без бәхетле» җыры исемдә калды. Татар теле укытучыларыбызга рәхмәт әйтәсем килә.

Укучыларыбызга киләчәктә дә уңышлар. Тагын да яхшырак укып, уеннарда да актив катнашып, туган телебездә камил сөйләшүләрен теләп калабыз.

***Энҗе ЗАЙДУЛЛИНА, туган тел һәм әдәбият укытучысы***

**Интервью**

# «Без галстука»: О ЧЁМ МЕЧТАЕТ ДИРЕКТОР?

**«У руля» школы «Адымнар-Нижнекамск» молодой и увлеченный своим делом руководитель – Артур Каримович Галиахметов. Несмотря на плотный рабочий график и большую занятость, он нашёл время для того, чтобы пообщаться с юными журналистами газеты «Адымнар Times» и ответить на более чем 20 вопросов. Публикуем самые интересные!**



**Ларина Иванова (5б): Кем Вы хотели стать в детстве?**

**Артур Каримович (далее – А.К.):** Врачом, а именно – хирургом. Знаете, у нас был друг семьи, который как раз работал хирургом. Когда я побывал на его рабочем месте, мне понравилась обстановка, и я решил – буду медиком. Хотелось помогать людям. Тогда мне было 7 лет. Это моя несбывшаяся мечта *(улыбается)*.

**Полина Сатенаева (6б): Какие предметы в школе Вас увлекали особенно?**

**А.К.:** А как вы думаете? *(Дети отвечают: «Химия, биология!»)* Ну, химия не очень, а биология – да! Моя мечта стать врачом меня мотивировала. Что касается более старших классов, то меня увлекли обществознание, право и история. Тогда передумал становиться врачом и выбрал профессию историка. Даже защищал кандидатскую диссертацию *(«Зарубежная историография национального движения в Поволжье и Приуралье в 1917-1918 годах», прим.ред.)*. История – очень увлекательная наука. В общем-то, все предметы в той или иной степени история, так как опираются на опыт прошлого.

**Розалина Николаева (6б): Какие оценки Вы получали в школе?**

**А.К.:** Учился хорошо, у меня в аттестате всего три четверки. Активно участвовал в олимпиадном движении. В своё время занял 3 место в РТ по истории. Кстати, именно через олимпиаду я понял, что значить достигать поставленных целей. Настоятельно рекомендую заняться этой темой: во-первых, вы уже начинаете готовиться к экзаменам, а во-вторых, определяетесь с выбором будущей профессии. Это очень классно! Чем раньше поймете, что вам нравится, тем легче будет в дальнейшем.

**Амина Халиуллина (5б): Как получилось, что Вы оказались в Нижнекамске и стали директором «Адымнар»?**

**А.К.:** Хороший вопрос! Вы знаете, никогда не думал, что буду жить и работать здесь. Нижнекамск – абсолютно новый для меня город, поэтому, когда в конце прошлого года мне позвонили с предложением возглавить новую школу, я сначала отказался. В тот момент я занимал хорошую должность в Казани, и мне не особо хотелось менять привычный образ жизни. Но мысль о новой школе – «Адымнар-Түбән Кама» – не давала мне покоя. Поэтому, когда меня повторно пригласили, я не смог сказать: «Нет».

**Самира Мавлиева (5б): Какие сложности возникли перед Вами перед открытием новой школы?**

**А.К.:** Тоже хороший вопрос! Без кого не может существовать школа? Правильно говорите – без учителей. Это очень важная задача для любого руководителя – сформировать коллектив, потому что именно от команды зависит, какой станет школа. Подбирать кадры было очень тяжело, практически каждый день я проводил собеседования с кандидатами. Спрашивал каждого, что конкретно нового они смогут внести в работу школы. Считаю, мы набрали хороших учителей. Вам нравится? *(Дети в голос отвечают: «Да!»)* Рад это слышать. Если вы так оцениваете, значит, всё было не зря. Другая сложность состояла в наборе детей – школа новая, родители и дети сомневались, что и как здесь будет. Нравится вам здесь учиться? *(Дети отвечают: «Да!»)* Ну вот, значит, всё сложилось.

**Полина Сатенаева (6б): Вы руководите большим коллективом. Как вам удаётся сплотить сотрудников?**

**А.К.:** Начал проводить тренинги для учителей. Большое значение имеет то, что мы делаем совместно, например, встречаем гостей. Эта работа сближает нас. Также с коллективом организовываем выезды. В этом помогает председатель профкома – Лилия Шамилевна *(Булатова, прим. ред.)* и её заместители. Мы уже ездили в Елабугу: побывали в исторических местах, заехали к коллегам в «Адымнар-Алабуга». Посетили Набережные Челны: русский драматический театр «Мастеровые» и встретились с коллегами из «Адымнар-Чаллы».

**Виктория Голякова (5б): Какой фильм Вы бы посоветовали посмотреть ученикам «Адымнар»?**

**А.К.:** В первую очередь, мультфильм «Кунг-фу Панда» *(смеется)*. Очень позитивный и мотивационный! А если что-то посерьезнее, то рекомендую фильм «История Рона Кларка». Есть фильмы, которые мне лично очень нравятся – «Заплати вперед» и «В погоне за счастьем». Они помогают поверить в себя. Эта философия заложена и в названии нашей школы – «Адымнар» *(«Адым» - в переводе с татарского языка «шаг», прим. ред.)* У нас есть такая фраза: «Адымнар» - путь к знаниям и согласию». Это значит, что нужно всегда стремиться навстречу к своей мечте.

**Алия Срурова (5б): О чём мечтает директор «Адымнар»?**

**А.К.:** Я хочу, чтобы каждый ребёнок, который обучается у нас, понял, какова миссия нашей школы: «Воспитание великого поколения». Вдумайтесь в эти слова! И моя мечта, связанная с «Адымнар», в этом и заключается: чтобы мы, учителя, глядя на каждого ребёнка, радовались его успехам, а дети, выпускаясь из нашей школы, говорили: «Я окончил школу «Адымнар-Түбән Кама» и горжусь этим!»



**Татарча сөйләшәбез**



## Артур ГАЛИӘХМӘТОВ:
# «МИНЕМ МИССИЯМ – УҢЫШКА ОМТЫЛЫШ УЯТУ!»

**Алия Срурова (5б): Директор булу авырмы?**

**А.К.:** Җиңел дип әйтмәс идем, ләкин, әлбәттә, мавыктыргыч! Яңа кешеләр, даими аралашу, иҗади проектлар - «Адымнар» мәктәбендә эшләү аеруча кызык. Мин инде башка мәктәптә директор, аннан соң Казанның 19нчы гимназиясендә мөдир ярдәмчесе булып эшләдем. Шул вакыт аралыгы эчендә һөнәремне дөрес сайлаганымны аңладым. Ни өчен икәнен беләсезме? Ул мине бәхетле итә, чөнки һәрвакыт югары нәтиҗәләргә омтылган һәм күпкә ирешергә теләгән укучылар белән эшлим. Әгәр дә мин, укытучы буларак, аларга алдагы һөнәрләрен сайлап алу процессында ярдәм итә алсам, куелган миссиям уңышлы булыр дип уйлыйм. Безнең балалар арасында булачак министрлар, хәтта президентлар, гомумән, дөньяны яхшы якка үзгәртәчәк кешеләр бар дип ышанам. Бу яктан, мин һәр укучыны үзгәрешләр агенты дип атарга теләр идем.

**Айзилә Хәсәншина (6б): Сезнең тормыш девизыгыз нинди?**

**А.К.:** Күңелемә түбәндәге сүзләр якын: «Әгәр дә мин янмасам, әгәр дә син янмасаң, бу дөньяны кем җылытыр?» Яшәвемнең девизы – уңышка омтылыш уяту. Шул яктан мәктәп, балаларны яңа үрләргә илһамландыру өчен бик яхшы мәйдан булып тора. Һәр укучының уңышка ирешүе өчен шартлар тудыру һәм бу юлда ярдәм итү – минем төп вазифам.

**Динара Абдуллина (5б): Сез нинди теллләр беләсез?**

**А.К.:** Дүрт телдә иркен сөйләшәм: татар, рус, инглиз һәм төрек. Америкада сәяхәт вакытында казахлар белән аралашу мөмкинлеге туды: мин татарча, ә алар-казакча сөйләште, гомумән, бер-беребезне яхшы аңладык. Үзбәк яки кыргыз телләрендә фильмнар карасам, тулысынча эчтәлеген аңлыйм.

**Аиша Хәйретдинова (5б): Сезнеңчә уңыш нәрсәдән гыйбарәт?**

**А.К.:** Иң төп күрсәткечләр – максатка ирешүчәнлек, бағланыш һәм үзсүзлелек.

**Розалина Николаева (6б): Буш вакытыгызны ничек үткәрергә яратасыз?**

**А.К.:** Гомумән, мотивацияне арттыра торган кинолар карарга яратам. Кайвакыт инглиз, кайвакыт исә төрек телендә карыйм. Әлбәттә, моның бер максаты бар - тел күнекмәләремне үстерү. Спорт белән шөгыльләнү өчен вакыт аерам, йөгерүне яратам. Гадәттә, һәр елның 31нче августында, 10 км йөгерергә тырышам – бу җәйге яллар исемлегемдәге соңгы этап булып тора. Шулай ук ашарга пешерергә яратам. Әлеге процесстан тәм табам.

**Айзиля Хәсәншина (6б): Укучыларны нинди сыйфатлары өчен хөрмәт итәсез?**

**А.К.:** Беренчедән, әлбәттә, тәртип. Икенчедән, укучыларның әхлакый сыйфатлары. Өченчедән, аларның белемнәре, һәм, дүртенчедән, укучы булганнары өчен инде. Кем соң ул укучы? Белем алырга теләүче кеше, ә ул, үз чиратында, хөрмәткә лаек.



**Question in English**

**Mavlieva Samira (5b): What are you expectations of Adymnar school in 10 years?**

A.K.: Well, it's a really interesting question, actually I thought about destiny of Adymnar-Nizhnekamsk for the nearest 5 years. I expect Adymnar school in Nizhnekamsk to be one of the best school in Tatarstan with a great number of successful pupils and their remarkable results.


Moreover, I want our children to become real agents of changes: so that they could change not only their own lives for the better ones but also lives of other people surrounding them.

**Шәхес**

# Эльвина УНВЕРЕН: «ИСТАНБУЛДАН – ТҮБӘН КАМАГА»

**«Төркия - симит һәм чәй, Босфор һәм акчарлаклар иле» шулай итеп татар һәм төрек телләре укытучысы Эльвина Айрат кызы Унверен әңгәмәсен башлап җибәрә. Ул Истанбулда бер елга якын яши һәм, Төркиядән кайткач, «Адымнар-Түбән Кама» мәктәбенә эшкә урнаша.**

**Бүген Эльвина Айрат кызы – «Адымнар Times» редакциясенең кунагы.**



**– Эльвина Айрат кызы, шунда ук сорау туа: Төркиягә ничек эләктегез?**

– Бу гүзәл ил белән беренче тапкыр 2017 нче елда таныштым. Төрек теле буенча XIII Бөтенроссия олимпиадасында җиңү яулаганнан соң Анкарада бер айлык стажировкага барырга тәкъдим иттеләр. Төркиядә уку вакытында бик күп авылларны һәм шәһәрләрне гиздек. Мәсәлән, Джумалыкызык һәм Алтынкёй авыллары; Истанбул, Конья, Бурса шәһәрләре. Нәкъ менә шул елда, ирем белән таныштым – бу вакыйга инститтутта булды. Берничә елдан соң без Төркиягә күчендек, шунда гаилә кордык.

**– Ни өчен төрек телен өйрәнү Сезнең өчен кызыклы?**

– Төрек теленә карата кызыксыну мәктәп елларында ук күренә башлады. Мәктәпне тәмамлагач, Казан (Идел буе) федераль университетына кердем. Өч тел арасында – инглиз, кытай, төрек сайлау мөмкинлеге бар иде. Төрек теле күңелемне әсир итте. Бу телне өйрәнү җиңел бирелде. Әлбәттә, университетыбызда бик яхшы укытучы бар иде – Рәсим Рәхимҗан улы Хәснетдинов. Төрек теле һәм мәдәниятенең гаҗәеп дөньясына чумуыма инде 8 ел үтте.

**– Сез бер елга якын Истанбулда яшәдегез. Төркиядә ничек көн итәләр?**

– Истанбул... Бу шәһәргә багышланган нинди генә шигырь юк! Истанбулдагы тормыш минем өчен акылга сыймаслык бер тәҗрибә булды! Бу шәһәр сайлаучан - барысын да үз итми. Андагы көнкүрешкә күнегү җиңел түгел, ләкин аерылу тагын да авыррак, Истанбулны онытырга мөмкин түгел! Әлбәттә, иң катлаулы мизгел, гаиләмнән аерым яшәү булды. Якыннарымны бик сагындым! Истанбул минем өемә әверелде, Аллаһка шөкер, икенче гаиләм барлыкка килде. Дөньяның теләсә кайсы почмагындагы кебек үк, төрек менталитеты үзенчәлекле. Телне белү, әлбәттә, адаптация процессын җиңеләйтә, ләкин шуңа да карамастан, кайчакта интонация буенча кешенең нәрсә әйтергә теләгәнен аңламаган вакытлар була. Бу күнекмәне бары тик чит илдә яшәп үстерергә мөмкин.

**– Төркиядә Сезгә барыннан да бигрәк нәрсә ошады?**

– Төркия – гаҗәп ил. Анда бик кунакчыл һәм ачык кешеләр яши, алар һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер. Төрекләр күршеләре белән бик тату. Хәтта урамда яшәүче хайваннар турында да кайгыртала. Кызык гадәтләрнен берсе шундый: бәйрәмнәр вакытында алар әлкән буынның янына килеп, кулларын үбә һәм, ихтирам йөзеннән, маңгаена куя. Гомумән, аларның бөтен бәйрәмнәре дә гаилә түрендә уза.

**– Эльвина Айрат кызы, кызыклы әңгәмә өчен рәхмәт сезгә! Сау булыгыз!**

– Чакыруыгыз өчен рәхмәт! Сау булыгыз.

***Әңгәмәне оештыручы Ксения ПУШКАРЁВА.***

***Фотосурәтләр Э. Унверенның архивыннан***

## «Үткәнеңне бел!»



6 А сыйныф укучылары өчен «Үткәнеңне бел!» диеп исемләнгән музей дәресе узды. Мин балаларга шәҗәрә турында мәгълүмат бирдем, күргәзмәгә куелган китаплар белән таныштырдым. Чарага Әлки районының хөрмәтле гражданины, Татарстанның атказанган икътисадчысы, мәртәбәле Аксакаллар Шурасы әгъзасы Мансур Корбангали улы Ганиев килде. Ул күп еллар дәвамында архив документлары аша ата-бабаларын барлап нәсел шәҗәрәсен, шулай ук Әлки һәм Түбән Кама районнарының шәҗәрәләрен төзегән кеше. Ул балаларга шәҗәрәләрен күрсәтте һәм төзү тәртибен аңлатты. Укучылар кызыксынып тыңлады, сораулар бирде.


***Әлфия КУЧКАЕВА, китапханә мөдире***



**Бизнес в «Адымнар»**

# РАСТИМ ПРЕДПРИНИМАТЕЛЕЙ

**В нашей школе проведение бизнес-завтраков уже стало традицией. Ребятам предоставилась уникальная возможность не только пообщаться с реальными бизнесменами, но и подготовить свои собственные бизнес-проекты.**



В гостях у нас уже побывали два известных нижнекамских предпринимателя: владелец сети пекарен «ПекАринка» Ильнар Сираев и гендиректор автоцентра «Эверест Авто» Радик Насибуллин. Они поделились с ребятами своими историями успеха. У каждого из них свой уникальный путь в бизнесе, однако оба уверены в одном: успех приходит к тем, кто много работает и, несмотря на ошибки, не опускает рук, а делает выводы и двигается вперед.

Юные адымнаровцы с интересом слушали рассказы опытных спикеров, а после презентовали свои бизнес-проекты. Производство хоккейных шайб и свечей, детский сад «Adymnar-babies», контент-фотостудия, компютерный игровой зал, изготовление брелоков из фанеры, настольные игры, украшения из бисера… Чего здесь только не было!

Так, например, ученик 7В класса Рамиль Шарипов рассказал нам о своей идее. Юноша решил разработать супердатчики в помощь для ориентирования в незнакомой местности. «Представим, что человек потерялся в путешествии и не знает, куда идти. С помощью датчика можно отправить сигнал в службу спасения, – говорит Рамиль. – Для взрослых датчик будет в виде браслета или кошелька, а для детей – значка или подвески. Их можно будет использовать даже в качестве зарядки для телефона». По мнению Рамиля, супердатчики не требуют больших затрат и будут актуальны для путешественников, лесников и грибников.



*Бизнес-завтраки в «Адымнар» будут продолжаться! О них мы будем рассказывать в следующих номерах газеты. Не пропустите!*

***Ксения ПУШКАРЁВА***

# В БИЗНЕСЕ – С ДЕТСТВА

**Владелец сети пекарен «ПекАринка» Ильнар Сираев начал проявлять себя как настоящий бизнесмен ещё в детстве. Об этом и многом другом он рассказал ребятам 5-х классов в рамках урока по финансовой грамотности.**



«Как стать успешным бизнесменом? Плюсы и минусы работы в собственном бизнесе» - именно этим темам была посвящена встреча, проводимая в формате диалога.


Посмотрев яркую презентацию, ребята активно задавали вопросы гостю. Так, например, они узнали, что Ильнар Сираев уже со школьной скамьи учился быть предпринимателем. А именно: скупал у бабушек, торгующих около магазина, газеты по 10 рублей и разносил их по подъездам. Прибыль за доставку газет «до квартиры» в 2 рубля оставлял себе. «Таким образом, жильцы уже знали, что каждую пятницу к ним придёт мальчик по имени Ильнар и принесет газету, - улыбаясь, вспоминает гость. – Да, люди готовы были покупать газету немного дороже, потому что я предоставлял сервис – никуда не нужно было ходить! Я экономил их время».

Кроме этого, Ильнар Сираев рассказал о том, какие навыки сформировали его характер, какой род деятельности в детском и подростковом возрасте привел к закладыванию черт будущего предпринимателя. Была проведена параллель между возможностями современных подростков и «детей из 90-х». Однако понятия «честность», «общительность», «трудолюбие», «нацеленность на результат» существуют вне времени – они вечны. Речь идет и о трудностях, которые возникают в процессе построения собственного бизнеса, а также путях их преодоления.

Ученики получили бесценный опыт живого общения с представителем бизнеса, поняли, что характер лидера, так необходимый при ведении личного дела, закладывается уже в подростковом возрасте. Участие в бизнес-проектах, презентациях, конкурсах и грантах – необходимый фундамент для развития своего потенциала в будущем.

***Лилия БУЛАТОВА, учитель истории и обществознания***

**Фотоальбом**



1Г сыйныфында беренче дәрес



Гарәп теле дәресе



Китапханә – иң яраткан урыныбыз

# КӨНКҮРЕШЕБЕЗ ҺӘМ БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ



Обладателем Гран-при (среди начальных классов) «Адымнар FEST» (Халыкара дуслык фестивале) стал 4 Г! На фестивале ребята представляли арабов



Обладателем Гран-при (среди старших классов) «Адымнар FEST» (Халыкара дуслык фестивале) стал 7 В! Ребята представляли русский народ




7В сыйныф укучысы Рөстәм Зиннуров мәктәбебезнең Президенты булaрак игълан ителде



«STEAM FEST» фәннәр фестивале кызыклы сынаулар һәм ачышлар белән балаларны шатландырды

Редактор, учитель русского языка и литературы – К. С. Пушкарёва.
Корректор, учитель русского языка и литературы – М. В. Халиуллина.
Консультант по фотоконтенту, учитель ИЗО – И. И. Мухаметгалиева.
Помощь в переводе и литературная правка на татарском и английком языках: Э. А. Унверен, Э. Ф. Зайдуллина, Г. Р. Муратова.
Редакция газеты благодарит за помощь всех педагогов и детей, принявших участие в выпуске первого номера газеты.

В газете размещены фото, сделанные педагогами и сотрудниками школы, а также взятые из открытых источников.
МБОУ "Адымнар-Нижнекамск", пр. Строителей, 66А.
423570, РТ, г. Нижнекамск
Телефон: 8 (8555)35-05-35.
E-Mail: adymnar.tk@inbox.ru

Отпечатано в ООО «ИПЦ «Гузель» г. Нижнекамск, пр. Химиков, д. 18, тел.: 8 (8555) 49-80-04
Заказ № 38227/22
Тираж 100 экз.
Декабрь, 2022 г.
Вёрстка и дизайн – И.И. Шалафаев

Мы в Telegram: adymnartubenkama
Мы в «ВКонтакте»: adymnartubenkama